**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәр муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Муниципальное образование**
**город Арск**
**Арского муниципального района Республики Татарстан**
**Совет города Арск**
**422000, РТ, г.Арск, площадь Советская, 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**КАРАР**

**« 25 » октябрь 2021 ел** **№ 6**

**Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Васильева Божа авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясын гамәлгә ашыру максатларында «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Васильева Божа авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 24 ноябрендә 16 сәг. 30 минутта Арча районы, Васильева Божа авылы, Магистраль урамы, 7/1 йорты (кибет яны) адресы буенча билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Васильева Божа авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 100 сум тәшкил иткән 80 яшьтән өлкәнрәкләрдән һәм 1 төркем инвалидлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

-Кыр урамындагы чишмәне төзекләндерү өчен материал сатып алу һәм аны ремонтлау?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

5. Арча муниципаль районы Васильева Божа авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Арча шәһәре башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны гражданнар күпләп җыела торган урында мәгълүмат стендында (Васильева Божа авылы, Магистраль урамы, 7/1 йорты), интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгы И.Г.Нуриев